| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

"17" август 2022 ел. № 20

# КАРАР

**Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Кышлау авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында " 2020 елның 25 мартындагы 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 нче номерлы " Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" гы карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән ) нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 25 мартындагы 4 нче номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Кышлау авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә" түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана";

1.2. 12 пунктның 2 абзацында "дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементлары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Кышлау авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: А.Х.Кашшапов